Эт- кешенең якын дусты.

# Эт- кешенең якын дусты.









# Овчарка - чик сакчысы



# Сөйлим сезгә әкият.

## Нәни йомгак!



Шулай беркөнне этебез Амур югалды. Эзләсәм дә таба алмадым. 2-3 көн үттеме, ишек алдында чия төстәге кечкенә йомгак тәгәрәп йөри. Уйный да, шаяра да үзе. Бераздан әнкәсе дә күренде. Әй уйнадылар үзләре.

- Агым судан йомгак алып кайттым әле, - дигән була Амур.

Мин аны чыннан да йомгак дип торам, ә ул аның көчек – малае булган.

# Этләр турында мәгълүматлар

- Дөньяда барлыгы 400 ләп эт токымы бар. Эт — кешенең тугры дусты һәм ярдәмчесе. Төньякта кеше һәм йөк ташу өчен җигелә торган этләр бар. Сукыр кешеләргә юл күрсәтүче этләр ярдәм итә . Милиционерга тәртип бозучыларны табышырга, көтүчегә көтү көтешергә дә этләр ярдәмгә килә. Сугыш вакытында этләр яралыларны коткарганнар, сугыш кирәк-яракларын һәм хәбәр ташыганнар... Токымлы этләр генә түгел, токымсызлары дә кешегә тугрылыклы хезмәт итәләр.
- Этне тәрбияләү җиңел түгел. Аны яхшы ашатырга, йонын тарап чистартырга, шәһәр җирендә булса, һавага алып чыгарга кирәк. Әгәр син эт асрарга ниятләгән булсаң, алдан ук шуны уйлап куй: боларның барысын да эшләргә вакытың һәм теләгең җитәрлекме? Юк икән, эт алмавың яхшырак булыр. Исеңдә тот: дүртаяклы дустыңның исәнлеге һәм гомере өчен кеше һәрвакыт җаваплы!

# Кечкенә этләр.











# Амур

**Авылда Амур атлы этебез бар. Махсус өйрәтүче булмаса да, ишегалдында аңардан да акыллы җан иясе юк. Күз карашыннан ук аңлый ул безне. Берәр ярамаган эш кылса, оясыннан да чыкмый. Чыкса да башын иеп кенә, күзләрен яшереп, кырын-кырын карап, койрыгын кысып басып тора.**










# Ә син беләсеңме?




**Белемеңне тикшер**

**1.** Такса. **2.** Колли. **3.** Йөнтәс (пудель).

# Уенчы эт

